## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Урман Асты Шонталасы авыл торак пунктында
2023 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2022 елның 13 октябреннән** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Урман Асты Шонталасы авыл торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елда Алексеевск муниципаль районының « Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Урман Асты Шонталасы авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1). Авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
2) .Тракторны карап тоту;
3).Урамнарны яктыртуны карап тоту;
4). Сууткәргеч челтәрләрен ремонтлау (материал сатып алу);
5).Чумдыру насосын сатып алу.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Урман Асты Шонталасы авыл җирлегенең Урман Асты Шонталасы авыл торак пунктындагы мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Җиһаншин

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ПОДЛЕСНО-ШЕНТАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОГРН 1021605753641
СОВЕТ ПОДЛЕСНО-ШЕНТАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
1605000819